| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2023 г.Зеленодольск № 273

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 23 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса,

җаваплылык чаралары турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 6 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президентыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгыннан (Рәисеннән) сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 10 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми Порталында (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ